**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Элки муниципаль районы**
**Базарлы-Матак авыл Жирлеге**

**башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Базарно-Матакского сельского поселения**
**Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422870, РТ Базарлы Матак авылы, Крайнов ур.,94 тел: 2-00-71

Адрес: 422870, РТ с.Базарные Матаки, ул.Крайнова, 94

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **Базарлы Матак авылы** **КАРАР**

2023 елның 07 сентябре № 11

Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегенең 2018 елның 24 августындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегенең «авыл торак пунктларында старосталар турында «гы нигезләмәне раслау хакында» 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2023 елның 6 февралендәге "Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 12-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 20 июле «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 236-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлеге башкарма комитеты Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авыл җирлегенең авыл торак пунктларында старосталар турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче бүлектә:

2.1 пункт. яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Авыл җирлеге старостасы авыл җирлеге гражданнары җыены тәкъдиме буенча муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә, аның составына әлеге авыл җирлеге керә. Авыл җирлеге старостасы әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары яки гражданнар җыены тәкъдим иткән көнне 18 яшькә җиткән һәм әлеге авыл җирлеге территориясендә урнашкан торак бинасы булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

2.2 пункт "муниципаль вазыйфа" сүзләреннән соң, «үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш,»сүзләр белән тулыландырырга";

2.3 пунктның 1 пунктчасы яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш, яки муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тыш;»

3 нче бүлекнең 4 нче пунктын 4.1) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

"4.1) авыл халкы өчен өстенлекле әһәмияткә ия булган мәсьәләләр буенча инициатив проект кертү инициативасы белән чыгыш ясау хокукына ия;»

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

Базарлы Матак авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Ф. Ф. Фәттахов